**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«22» июнь 2016 ел　　　　Сәмәкәй авылы　　　　№ 18

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210 - ФЗ Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Сәмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге турында» 2013 елның 7 февралендәге 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе　　　　З.М. Сәгыйтов